СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ**
10 июля 2015 года

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
№539

2014 елда Зеленодольск муниципаль районында өлкән яшьтәге халыкның аерым төркемнәрен диспансерлаштыру чараларын тормышка ашыру турында

2014 елда өлкән яшьтәге халыкның аерым төркемнәрен диспансерлаштыру чараларын гамәлгә ашыру турында «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең баш табибы И.Р. Һидиятовның мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Зеленодольск муниципаль районы Советы хезмәткәрләрнең һөнәри сәламәтлеген саклау, авырулар һәм имгәнүләр дәрәҗәсен киметү иң мөһим юнәлешләр булып тора, икътисади өлешне тәэмин итәчәк, дип билгеләп үтә.

Диспансерлаштыруда шәһәр һәм районның участок-территориаль принцибы буенча эшләүче 10 дәвалау-профилактика учреждениесе катнашты.

Диспансерлаштыруны узган гражданнарның саны арту һәм аларны сәламәтлек төркемнәре буенча бүлү буенча атналык мониторинг уздырылды.

Диспансерлаштыру барышында авырулар ачыкланган барлык затлар да өстәмә тикшерү һәм дәвалауга юнәлтелгән.

Зеленодольск муниципаль районында гражданнарның тормыш-көнкүрешен һәм сәламәтлеген саклауга юнәлдерелгән өлкән кешеләрнең аерым төркемнәрен диспансерлаштыру чараларын исәпкә алып, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. 2014 елда өлкән яшьтәге халыкның аерым төркемнәрен диспансерлаштыру чараларын гамәлгә ашыру турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына социаль партнерлык һәм төрле ведомстволар, иҗтимагый оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары хезмәттәшлеге нигезендә өлкән яшьтәге халыкның аерым төркемнәрен диспансерлаштыру чараларын тормышка ашыруны тәэмин итү эшен дәвам итәргә.

3. Тәкъдим итәргә:

3.1. "Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә:

- Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы хөкүмәтләренең регламентлаучы документлары таләпләре нигезендә өлкән яшьтәге халыкның аерым төркемнәрен диспансерлаштыру тәртибен үтәргә;

- өлкән яшьтәге халыкның аерым төркемнәрен диспансерлаштыру чараларын гамәлгә ашыру максатларында профилактик юнәлеш буенча эшне көчәйтергә.

3.2. Зеленодольск муниципаль районы предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләренә, оештыру-хокукый формасына һәм милек формасына карамастан, гамәлдәге законнар нигезендә, диспансерлаштыруны узу өчен шартлар тәэмин итәргә;

3.3. массакүләм мәгълүмат чараларына Зеленодольск муниципаль районы территориясендә диспансерлаштыруның максатлары һәм бурычлары турында мәгълүмат урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Советының социаль мәсьәләләр һәм сәламәтлек саклау буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**